**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«05» июнь 2024 ел Мусабай-Завод авылы № 9

«Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 5 маендагы 7 номерлы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 5 маендагы 7 номерлы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2.1. Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формадагы запросның һәр кырын тутыру процессында башкарыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы запросның дөрес тутырылмаган кыры ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр аша запросның электрон формасында турыдан туры хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе З.З. Хесәинова